# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**Об отдельных мерах по обеспечению качества и безопасности пищевых продуктов в Республике Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
3 ноября 2016 года

Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона и правовая основа обеспечения качества и безопасности пищевых продуктов в Республике Татарстан**

1. Настоящий Закон регулирует отношения в области обеспечения качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий, контактирующих с пищевыми продуктами (далее – материалы и изделия), изготавливаемых и (или) находящихся в обороте на территории Республики Татарстан, устанавливает отдельные меры по обеспечению качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий, а также правовые основы взаимодействия органов государственной власти Республики Татарстан с органами местного самоуправления и организациями в целях повышения качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий, производимых и (или) реализуемых на территории Республики Татарстан.

2. Правовую основу обеспечения качества и безопасности пищевых продуктов в Республике Татарстан составляют Конституция Российской Федерации, Конституция Республики Татарстан, Федеральный закон от 2 января 2000 года № 29-ФЗ «О качестве и безопасности пищевых продуктов» (далее – Федеральный закон № 29-ФЗ), иные нормативные правовые акты Российской Федерации, настоящий Закон, иные нормативные правовые акты Республики Татарстан.

3. Понятия, используемые в настоящем Законе, применяются в тех же значениях, что и в Федеральном законе № 29-ФЗ и иных федеральных законах.

Статья 2. **Меры по обеспечению качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий**

Качество и безопасность пищевых продуктов, материалов и изделий в Республике Татарстан обеспечиваются в том числе посредством:

1) проведения физическими или юридическими лицами, осуществляющими деятельность по изготовлению и обороту пищевых продуктов, материалов и изделий, организационных, агрохимических, ветеринарных, технологических, инженерно-технических, санитарно-противоэпидемических и фитосанитарных мероприятий по выполнению требований нормативных документов к пищевым продуктам, материалам и изделиям, условиям их изготовления, хранения, перевозок и реализации;

2) проведения производственного контроля за качеством и безопасностью пищевых продуктов, материалов и изделий, условиями их изготовления, хранения, перевозок и реализации;

3) внедрения системы «Национальная торговая марка» путем учреждения в Республике Татарстан информационного знака «Национальная торговая марка» и определения порядка его использования;

4) применения мер по пресечению нарушений законодательства Российской Федерации и Республики Татарстан в сфере обеспечения качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий, в том числе нарушений требований нормативных документов, а также применения мер гражданско-правовой, административной и иной ответственности к лицам, виновным в совершении указанных нарушений;

5) оказания помощи в продвижении на рынке пищевых продуктов, материалов и изделий организаций или индивидуальных предпринимателей в Республике Татарстан, соответствующих требованиям качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий;

6) содействия росту конкурентоспособности пищевых продуктов и продвижению на рынке органической пищевой продукции, сырья и продовольствия;

7) информирования населения через средства массовой информации и (или) информационно-телекоммуникационную сеть «Интернет» о качестве и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий;

8) применения иных мер обеспечения качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий, установленных законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

Статья 3. **Полномочия Кабинета Министров Республики Татарстан в сфере обеспечения качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий**

К полномочиям Кабинета Министров Республики Татарстан в сфере обеспечения качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий относятся:

1) принятие нормативных правовых актов Республики Татарстан, направленных на поддержку обеспечения качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий;

2) взаимодействие с федеральными органами государственной власти, органами местного самоуправления, иными органами и организациями с целью

обеспечения качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий;

3) создание и организация деятельности Межведомственного координационного совета по вопросам обеспечения повышения качества и безопасности пищевых продуктов (далее также – Координационный совет);

4) организация и содействие развитию системы «Национальная торговая марка», а также организация деятельности государственного унитарного предприятия Республики Татарстан «Национальная торговая марка» (далее – Республиканский центр качества);

5) утверждение порядка получения и лишения права использования информационного знака «Национальная торговая марка», а также требований к получению информационного знака «Национальная торговая марка» по предложениям Координационного совета;

6) организация мероприятий, направленных на стимулирование повышения производителями качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий, в том числе маркированных информационным знаком «Национальная торговая марка»;

7) осуществление иных полномочий, предусмотренных законодательством Российской Федерации, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, законодательством Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан.

Статья 4. **Полномочия органов исполнительной власти Республики Татарстан в сфере обеспечения качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий**

К полномочиям органов исполнительной власти Республики Татарстан в сфере обеспечения качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий в пределах их компетенции относятся:

1) участие в разработке и реализации нормативных правовых актов Республики Татарстан, направленных на поддержку обеспечения качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий;

2) взаимодействие с федеральными органами государственной власти, органами местного самоуправления, Республиканским центром качества, иными организациями с целью обеспечения качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий;

3) разработка предложений по проведению мероприятий, направленных на стимулирование повышения качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий, увеличение качественных и безопасных пищевых продуктов в целях повышения продолжительности жизни населения и уменьшения воздействия факторов, негативно влияющих на здоровье человека;

4) содействие развитию системы «Национальная торговая марка»;

5) выработка дифференцированных, в зависимости от места проживания, трудовой деятельности, половозрастных и иных особенностей, медицинских показаний для отдельных групп населения, рекомендаций к качеству и составу пищевых продуктов;

6) осуществление регионального государственного ветеринарного надзора, регионального государственного экологического надзора;

7) осуществление иных полномочий, предусмотренных законодательством Российской Федерации, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, законодательством Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан.

Статья 5. **Требования к обеспечению качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий**

Предназначенные для реализации пищевые продукты должны отвечать требованиям, установленным Федеральным законом № 29-ФЗ и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации и нормативными правовыми актами Республики Татарстан.

Статья 6. **Информационный знак «Национальная торговая марка»**

1. В целях обеспечения качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий в Республике Татарстан учреждается информационный знак «Национальная торговая марка».

2. Маркировка пищевых продуктов информационным знаком «Национальная торговая марка» информирует население о том, что данные пищевые продукты не содержат генномодифицированных организмов, отвечают установленным нормативными документами требованиям к качеству и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий, соответствуют по составу и нормам сырьевых компонентов требованиям, определенным Кабинетом Министров Республики Татарстан в соответствии с пунктом 5 статьи 3 настоящего Закона.

3. Производители пищевых продуктов независимо от организационно-правовых форм, форм собственности и местонахождения имеют право на равной, добровольной основе в заявительном порядке обратиться в Республиканский центр качества за получением права использования информационного знака «Национальная торговая марка».

4. Порядок получения и лишения права использования информационного знака «Национальная торговая марка», а также требования к получению информационного знака «Национальная торговая марка» утверждаются Кабинетом Министров Республики Татарстан с учетом предложений Координационного совета.

5. Информационный знак «Национальная торговая марка» подлежит правовой защите в порядке, установленном законодательством.

Статья 7. **Республиканский центр качества**

1. В целях стимулирования повышения качества и безопасности пищевых продуктов в Республике Татарстан Кабинетом Министров Республики Татарстан создается Республиканский центр качества, являющийся юридическим лицом в

организационно-правовой форме государственного унитарного предприятия.

2. Республиканский центр качества осуществляет свою деятельность в соответствии с предметом и целями, определенными в уставе Республиканского центра качества, утвержденном Кабинетом Министров Республики Татарстан.

Статья 8. **Межведомственный координационный совет по вопросам обеспечения повышения качества и безопасности пищевых продуктов**

1. Межведомственный координационный совет по вопросам обеспечения повышения качества и безопасности пищевых продуктов является коллегиальным совещательным органом, создаваемым в целях обеспечения эффективного взаимодействия органов государственной власти Республики Татарстан, уполномоченных федеральных органов исполнительной власти, органов местного самоуправления, Республиканского центра качества, производителей пищевых продуктов и их объединений, перерабатывающих и торговых, экспертных и иных организаций по вопросам обеспечения качества и безопасности пищевых продуктов на территории Республики Татарстан.

2. Задачами Координационного совета являются обеспечение повышения качества и безопасности пищевых продуктов в Республике Татарстан, рассмотрение направлений развития системы «Национальная торговая марка» и предложений по ее совершенствованию, вопросов, возникающих в процессе функционирования системы.

3. Состав Координационного совета и положение о Координационном совете утверждаются Кабинетом Министров Республики Татарстан.

4. К полномочиям Координационного совета относятся:

1) анализ статистических и иных материалов и информации, касающихся обеспечения повышения качества и безопасности пищевых продуктов, их производства и оборота на территории Республики Татарстан;

2) разработка мер по повышению качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий в Республике Татарстан;

3) внесение предложений в Кабинет Министров Республики Татарстан о порядке получения и лишения права использования информационного знака «Национальная торговая марка», а также разработка и внесение требований к получению информационного знака «Национальная торговая марка»;

4) разработка рекомендаций:

а) по увеличению выпуска и реализации на территории Республики Татарстан пищевых продуктов, маркированных информационным знаком «Национальная торговая марка»;

б) по проведению новых видов исследований в целях выявления вредных для здоровья и жизни человека пищевых и иных добавок, а также фактов фальсификации продукции;

в) по совершенствованию нормативных правовых актов в сфере обеспечения качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий;

5) информирование населения через средства массовой информации и (или) информационно-телекоммуникационную сеть «Интернет» по вопросам обеспечения

повышения качества и безопасности пищевой продукции;

6) формирование предложений по развитию системы «Национальная торговая марка».

5. Для осуществления своих функций Координационный совет имеет право:

1) запрашивать от органов государственной власти, организаций и граждан необходимую информацию по вопросам обеспечения повышения качества и безопасности пищевой продукции;

2) давать разъяснения по вопросам, входящим в компетенцию Координационного совета;

3) приглашать на заседания представителей органов государственной власти, общественных и иных заинтересованных организаций и граждан;

4) привлекать в установленном порядке экспертов, а также представителей научно-исследовательских, проектных и образовательных организаций;

5) образовывать рабочие группы, комиссии по вопросам обеспечения повышения качества и безопасности пищевой продукции.

Статья 9. **Финансирование мероприятий по обеспечению качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий**

Финансирование мероприятий по обеспечению качества и безопасности пищевых продуктов, материалов и изделий осуществляется за счет средств бюджета Республики Татарстан, внебюджетных источников, в том числе средств физических и юридических лиц, осуществляющих деятельность по производству пищевых продуктов, в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

Статья 10. **Порядок вступления в силу настоящего Закона**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан привести свои нормативные правовые акты в соответствие с настоящим Законом, а также принять нормативные правовые акты, обеспечивающие реализацию настоящего Закона, в течение трех месяцев со дня вступления в силу настоящего Закона.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ / ГОМУМИ БУЛЕК — АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казань, Кремль
17 ноября 2016 года
№ 82-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүнең аерым чаралары турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 3 ноябрендә
кабул ителде

## 1 статья. Әлеге Законның җайга салу предметы һәм Татарстан Республикасында азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүнең хокукый нигезе

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелә торган һәм (яисә) әйләнештә булган азык-төлек продуктларының, азык-төлек продуктлары белән контактта була торган материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең (алга таба – материаллар һәм алар өчен кулланыла торган әйберләр) сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга сала, азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүнең аерым чараларын, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелә һәм (яисә) реализацияләнә торган азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын яхшырту һәм куркынычсызлыгын арттыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының җирле үзидарә органнары һәм оешмалар белән үзара эшчәнлегенең хокукый нигезләрен билгели.

2. Татарстан Республикасында азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүнең хокукый нигезен Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, “Азык-төлек продуктларының сыйфаты һәм куркынычсызлыгы турында” 2000 елның 2 гыйнварындагы 29-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 29-ФЗ номерлы Федераль закон), Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары тәшкил итә.

3. Әлеге Законда кулланылган төшенчәләр 29-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнардагы мәгънәләрендә кулланылалар.

2 статья. **Азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын һәм іуркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары**

Татарстан Республикасында азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфаты һәм куркынычсызлыгы шул исәптән түбәндәге юллар белән тәэмин ителә:

1) азык-төлек продуктларын, материалларны һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрне җитештерү һәм аларның әйләнеше буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы физик яисә юридик затлар тарафыннан азык-төлек продуктларына, материалларга һәм алар өчен кулланыла торган әйберләргә карата, аларны ясау, саклау, ташу һәм реализацияләү шартларына карата норматив документлар таләпләрен үтәү буенча оештыру, агрохимия, ветеринария чаралары, технологик, инженер-техник, эпидемиягә каршы, санитария һәм фитосанитария чараларын үткәрү;

2) азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатына һәм куркынычсызлыгына, аларны әзерләү, саклау, ташу һәм реализацияләү шартларына производство контроле үткәрү;

3) “Милли сәүдә маркасы” мәгълүмат тамгасын һәм аны куллану тәртибен билгеләү юлы белән Татарстан Республикасында “Милли сәүдә маркасы” системасын гамәлгә кертү;

4) азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын, шул исәптән норматив документлар таләпләрен бозуларны булдырмау чараларын күрү, шулай ук күрсәтелгән хокук бозуларны кылуда гаепле затларга карата граждани-хокукый, административ һәм башка җаваплылык чараларын күрү;

5) базарда Татарстан Республикасындагы оешмаларның һәм индивидуаль эшкуарларның азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфаты һәм куркынычсызлыгы таләпләренә туры килә торган азык-төлек продуктлары, материаллары һәм алар өчен кулланыла торган әйберләре сатылуны яхшыртуга ярдәм итү;

6) азык-төлек продуктларының конкурентлыкка сәләтен үстерүгә һәм базарда органик азык-төлек продукциясе, чималы һәм азык-төлек сатылуны яхшыртуга булышу;

7) азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфаты һәм куркынычсызлыгы турында халыкка массакүләм мәгълүмат чаралары һәм (яисә) “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша хәбәр итү;

8) азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүнең Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән башка чараларын күрү.

3 статья. **Азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын кабул итү;

2) азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү максатында федераль дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, башка органнар һәм оешмалар белән үзара эшчәнлек итү;

3) Азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын арттыруны тәэмин итү мәсьәләләре буенча ведомствоара координация советы (алга таба шулай ук – Координация советы) булдыру һәм аның эшчәнлеген оештыру;

4) “Милли сәүдә маркасы” системасын оештыру һәм аның үсешенә ярдәм итү, шулай ук “Милли сәүдә маркасы” Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе (алга таба – Республика сыйфат үзәге) эшчәнлеген оештыру;

5) “Милли сәүдә маркасы” мәгълүмат тамгасын куллану хокукын бирү һәм бу хокуктан мәхрүм итү тәртибен, шулай ук Координация советы тәкъдимнәре буенча “Милли сәүдә маркасы” мәгълүмат тамгасын алуга таләпләрне раслау;

6) азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең, шул исәптән “Милли сәүдә маркасы” мәгълүмат тамгасы куелганнарның сыйфатын һәм куркынычсызлыгын җитештерүчеләр тарафыннан арттыруны кызыксындыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру;

7) Россия Федерациясе законнарында, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган бүтән вәкаләтләрне башкару.

4 статья. **Азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләре**

Азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының үз компетенцияләре чикләрендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

2) азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү максатында федераль дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, Республика сыйфат үзәге, башка оешмалар белән үзара эшчәнлек итү;

3) халыкның гомер озынлыгын арттыру һәм кеше сәламәтлегенә тискәре йогынты ясаучы факторлар тәэсирен киметү максатларында азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын арттыруны кызыксындыруга, сыйфатлы һәм куркыныч булмаган азык-төлек продуктларын арттыруга юнәлдерелгән чаралар үткәрү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

4) “Милли сәүдә маркасы” системасы үсешенә ярдәм итү;

5) азык-төлек продуктларының сыйфатына һәм составына карата яшәү урынына, хезмәт эшчәнлегенә, җенес, яшь үзенчәлекләренә һәм башка үзенчәлекләргә, халыкның аерым төркемнәре өчен медицина күрсәтмәләренә бәйле рәвештә дифференциацияле тәкъдимнәр эшләү;

6) региональ дәүләт ветеринария күзәтчелеген, региональ дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру;

7) Россия Федерациясе законнарында, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган бүтән вәкаләтләрне башкару.

5 статья. **Азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүгә таләпләр**

Реализацияләү өчен каралган азык-төлек продуктлары 29-ФЗ номерлы Федераль законда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирергә тиеш.

6 статья. **“Милли сәүдә маркасы” мәгълүмат тамгасы**

1. Татарстан Республикасында азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында “Милли сәүдә маркасы” мәгълүмат тамгасы гамәлгә кертелә.

2. Азык-төлек продуктларына “Милли сәүдә маркасы” мәгълүмат тамгасы куелу халыкка бу азык-төлек продуктларында модификацияләнгән генлы

организмнар булмау, аларның азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатына һәм куркынычсызлыгына норматив документларда каралган таләпләргә җавап бирүе, чимал компонентларының составы һәм нормалары буенча әлеге Законның 3 статьясындагы 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән таләпләргә туры килүе хакында мәгълүмат бирә.

3. Азык-төлек продуктларын җитештерүчеләр, оештыру-хокукый рәвешләренә, милек төренә һәм урнашкан урыннарына бәйсез рәвештә, “Милли сәүдә маркасы” мәгълүмат тамгасын куллану хокукы бирүне сорап, гомуми, ихтыярый нигездә заявка бирү тәртибендә Республика сыйфат үзәгенә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

4. “Милли сәүдә маркасы” мәгълүмат тамгасын куллану хокукын бирү һәм бу хокуктан мәхрүм итү тәртибе, шулай ук “Милли сәүдә маркасы” мәгълүмат тамгасын алуга таләпләр, Координация советы тәкъдимнәрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

5. “Милли сәүдә маркасы” мәгълүмат тамгасы законнарда билгеләнгән тәртиптә хокукый яклanырга тиеш.

7 статья. **Республика сыйфат үзәге**

1. Татарстан Республикасында азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын арттыруны кызыксындыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Республика сыйфат үзәге оештырыла, ул оештыру-хокукый яктан дәүләт унитар предприятиесе рәвешендә төзелгән юридик зат булып тора.

2. Республика сыйфат үзәге үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган Республика сыйфат үзәге уставында билгеләнгән предмет һәм максатлар нигезендә гамәлгә ашыра.

8 статья. **Азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын арттыруны тәэмин итү мәсьәләләре буенча ведомствоара координация советы**

1. Азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын арттыруны тәэмин итү мәсьәләләре буенча ведомствоара координация советы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнарының, җирле үзидарә органнарының, Республика сыйфат үзәгенең, азык-төлек продуктларын җитештерүчеләрнең һәм аларның берләшмәләренең, эшкәртү, сәүдә, эксперт оешмаларының һәм башка оешмаларның Татарстан Республикасы территориясендә азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре буенча нәтиҗәле үзара эшчәнлеген тәэмин итү максатларында төзелә торган коллегиаль киңәшмә орган булып тора.

2. Координация советы бурычлары Татарстан Республикасында азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын арттыруны тәэмин итүдән, “Милли сәүдә маркасы” системасын үстерү юнәлешләрен һәм аны камилләштерү буенча тәкъдимнәрне, система эшләве барышында барлыкка килә торган мәсьәләләрне караудан гыйбарәт.

3. Координация советы составы һәм Координация советы турында нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

4. Координация советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы территориясендә азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын арттыруны тәэмин итүгә, аларны җитештерүгә һәм аларның әйләнешенә кагылышлы статистика мәгълүматларын һәм башка материалларны, мәгълүматны анализлау;

2) Татарстан Республикасында азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын арттыру чараларын эшләү;

3) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына “Милли сәүдә маркасы” мәгълүмат тамгасын куллану хокукын бирү һәм бу хокуктан мәхрүм итү тәртибе турында тәкъдимнәр кертү, шулай ук “Милли сәүдә маркасы” мәгълүмат тамгасын алуга таләпләр эшләү һәм кертү;

4) түбәндәге тәкъдимнәрне эшләү:

а) “Милли сәүдә маркасы” мәгълүмат тамгасы куелган азык-төлек продуктларын Татарстан Республикасы территориясендә җитештерүне һәм реализацияләүне арттыру буенча;

б) кешенең сәламәтлеге һәм тормышы өчен куркыныч азык-төлек өстәмәләрен һәм башка өстәмәләрне, ялган продукция ясау фактларын ачыклау максатларында яңа төр тикшеренүләр үткәрү буенча;

в) азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә норматив хокукый актларны камилләштерү буенча;

5) азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын арттыруны тәэмин итү мәсьәләләре буенча массакүләм мәгълүмат чаралары һәм (яисә) “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша халыкка хәбәр итү;

6) “Милли сәүдә маркасы” системасын үстерү буенча тәкъдимнәр әзерләү.

5. Үз функцияләрен үтәү өчен Координация советы түбәндәге хокукларга ия:

1) дәүләт хакимияте органнарыннан, оешмалардан һәм гражданнардан азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын арттыруны тәэмин итү мәсьәләләре буенча кирәкле мәгълүматны соратып алу;

2) Координация советы компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирү;

3) утырышларга дәүләт хакимияте органнары вәкилләрен, иҗтимагый оешмалар һәм кызыксынучы башка оешмалар вәкилләрен чакыру;

4) билгеләнгән тәртиптә экспертларны, шулай ук фәнни-тикшеренү, проектлау һәм белем бирү учреждениеләре вәкилләрен җәлеп итү;

5) азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын арттыруны тәэмин итү мәсьәләләре буенча эшче төркемнәр оештыру.

9 статья. **Азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын финанслау**

Азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, бюджеттан тыш чыганаклар, шул исәптән азык-төлек продуктларын җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы физик һәм юридик затларның акчалары исәбеннән Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башкарыла.

10 статья. **Әлеге Законның үз көченә керү тәртибе**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты                                                                 Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2016 елның 17 ноябре
№ 82-ТРЗ